| СОВЕТ КУГУШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**9 февраль 2023 ел** Күгеш авылы **№ 119**

Күгеш авыл җирлеге Советының «2023 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгеш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында» 2023 елның 16 гыйнварындагы 112 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Күгеш авыл җирлеге Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы " җирлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. «2023 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгеш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында» 2023 елның 16 гыйнварындагы 112 номерлы Күгеш авыл җирлеге Советы карарының 1 пунктында «яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча» сүзләрнен төшереп калдырырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) “Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Күгеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1 йорт(администрация бинасы), Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1а йорт (СДК бинасы) урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Күгеш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Күгеш авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе:** **А. А. Гатауллин**